**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2023 ел, 4 сентябрь № 204

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Бакырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2022 елның 19 декабрендәге 143 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Бакырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Шәһәр төзелеше регламентлары махсус икътисадый зоналар һәм алгарышлы үсеш территорияләре чикләрендә урнашкан урман фонды җирләре, җир өсте сулары, запас җирләре, махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләре, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, җир кишәрлекләре өчен билгеләнми.».

2. Әлеге карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш, төзекләндерү, ТКХ һәм инфраструктура үсеше буенча комиссиягә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы Башлыгы**
**Апас муниципаль районы**
**Советы рәисе А.Г. Җиһаншин**